МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.09.2022 Казан шәһәре № 340

Кара металл һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлегенә федераль дәүләт лицензия контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазенең (җаваплары контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында дәлилли торган контроль сорауларның исемлеген) формасын раслау турында

«Кара һәм төсле металл ватыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләүнең, шулай ук кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2022 елның 28 маендагы 980 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Кара металл һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлегенә федераль дәүләт лицензия контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазенең (җаваплары контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында дәлилли торган контроль сорауларның исемлеген) кушымта итеп бирелгән формасын расларга.

2. «Кара металл һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлегенә федераль дәүләт лицензия контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләренең (җаваплары контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында дәлилли торган контроль сорауларның исемлекләре) формаларын раслау турында» 2022 елның 09 мартындагы 89 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

**Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары – икътисад министры** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елның 16 сентябрендәге 340 номерлы боерыгы белән расланды

Форма

QR-код төшерү өчен урын

Кара металл һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлегенә федераль дәүләт лицензия контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (җаваплары контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында дәлилли торган контроль сорауларның исемлеге)

1. Федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләренең бердәм реестрына кертелгән контроль төре атамасы: Кара металл, төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлегенә федераль дәүләт лицензия контроле (күзәтчелеге) ___________________________

2. Контроль (күзәтчелек) органының исеме: Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы _______________________________________________________

3. Тикшерү кәгазе формасын раслау турында норматив хокукый акт реквизитлары: Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының ___ _ _ _ _ _ _ _ _ _____ номерлы боерыгы

4. Контроль (күзәтчелек) чара төре ________________________________

5. Контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрелә торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты ________________________________________

6. Контроль үткәрелүче зат:

Шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) ___________________________________________________________________________

Салым түләүченең идентификация номеры һәм (яки) шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры _____________________________________________________

Шәхси эшкуарның теркәлү адресы _________________________ ___________________________________________________________________________ ___________________________________________________________________________

Юридик затның атамасы __________________________________________ ___________________________________________________________________________

Салым түләүченең идентификация номеры һәм (яки) төп дәүләт теркәү номеры _____________________________________________________

Юридик затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) адресы _________________________________________________

______________________________________________________________________

7. Тикшерү кәгазен тутырып, контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү урыны (урыннары) ______________________________________________________

8. Контроль (күзәтчелек) органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында контроль (күзәтчелек) органының карары реквизитлары _____________________

9. Контроль (күзәтчелек) чарасының хисап номеры ____________________

10. Контроль (күзәтчелек) органының контроль (күзәтчелек) чараны үткәрүче һәм тикшерү кәгазен тутыручы вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары _______________________________________________________

11. Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган, җаваплары контроль үткәрелә торган затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында дәлилле торган контроль сорауларның исемлеге

| № т/б | Контроль сораулар исемлеге | Әлеге актларның структур берәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актлар реквизитлары | Әйе | Юк | Таләп ителми | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Объектта лицензияле эшчәнлек башкару өчен кирәкле милек хокукында яки бүтән законлы нигездә җир кишәрлеге һәм (яки) бина, төзелмә, корылма, бүлмә бармы? | «Кара һәм төсле металл ватыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләүнең, шулай ук кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2022 елның 28 маендагы 980 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Кара һәм төсле металл ватыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмәнең 5 пунктындагы «а» пунктчасы (алга таба – Лицензияләү турында нигезләмә) | | | | |
| 2 | Объектта лицензияле эшчәнлек башкару өчен кирәкле милек хокукында яки бүтән законлы нигездә техник чаралар, җиһазлар һәм техник документлар бармы? | Лицензияләү турында Нигезләмәнең 5 пунктындагы «а» пунктчасы | | | | |
| 3 | Объектта кара һәм (яки) төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын саклау өчен каралган асфальт, бетон яки башка каты дымга чыдам катлам белән ябылган мәйдан бармы? | Лицензияләү турында Нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасы «Кара һәм төсле металл ватыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләүнең, | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | шулай ук кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2022 елның 28 маендагы 980 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 9 пунктының бишенче абзацы (алга таба – Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре) | | | | |
| 4 | Объектта Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм алардан читләштерү кагыйдәләре таләпләренә туры китереп тиешле әзерлек һәм аттестация узган хезмәт килешүләре төзегән хезмәткәрләр бармы? | Лицензияләү турында Нигезләмәнең 5 пунктындагы «б» пунктчасы | | | | |
| 5 | Объектта күренә торган урында Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 4 пунктында каралган мәгълүмат бармы:<br>- юридик зат өчен – исеме һәм төп дәүләт теркәү номеры, телефон номеры,<br>- шәхси эшкуар өчен – шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, фамилиясе, исеме, атасының исеме ( булса), телефон номеры;<br>- кара һәм (яки) төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итүгә җаваплы зат турында мәгълүматлар;<br>- эш тәртибе;<br>- кара һәм (яки) төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү шартлары һәм бәяләре; | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 4 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | - физик затлардан кабул итәргә рөхсәт ителгән төсле металл ватыклары һәм калдыклары исемлеге;<br>- лицензияләр реестрында гамәлдәге лицензия турында белешмәләр булган язмага сылтама? | | | | | |
| 6 | Объектта Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 4 пунктында каралган документлар бармы:<br>- объектта кара һәм (яки) төсле металл ватыкларында һәм калдыкларында радиация булу-булмауга тикшерү үткәрү тәртибе турында инструкция яисә аның юридик затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган күчермәсе;<br>- кара һәм (яки) төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын шартлау куркынычсызлыгына тикшерү тәртибе турында инструкция яисә аның юридик затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган күчермәсе;<br>- кара һәм (яки) төсле металл ватыкларында һәм калдыкларында радиация булуны ачыклаган очракта гамәлләр тәртибе турында инструкция яисә аның юридик затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган күчермәсе;<br>- шартлаткыч предметлар табылганда гамәлләр тәртибе турында инструкция яисә аның юридик затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган күчермәсе? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 5 пункты | | | | |
| 7 | Объектта милек хокукында яисә башка законлы нигездә радиация контроле үткәрү өчен, алар турында Үлчәүләрнең бердәмлеген тәэмин итү буенча федераль мәгълүмат фондында белешмәләр булган һәм Үлчәү бердәмлеген тәэмин итү | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 9 пунктының алтынчы абзацы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тикшерелгән үлчәү чаралары бармы? | | | | | |
| 8 | Объектта милек хокукында яисә башка законлы нигездә, алар турында Үлчәүләрнең бердәмлеген тәэмин итү буенча федераль мәгълүмат фондында белешмәләр булган һәм Үлчәү бердәмлеген тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тикшерелгән авырлык үлчәү чаралары бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 9 пунктының җиденче абзацы | | | | |
| 9 | Объектта II разрядтан түбән булмаган квалификацияле металл ватыклары һәм калдыклары контролеры бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 9 пунктының икенче абзацы | | | | |
| 10 | Объектта кара һәм (яки) төсле металл калдыкларында радиация булу-булмауга тикшерү үткәрү өчен җаваплы зат бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 9 пунктының өченче абзацы | | | | |
| 11 | Объектта кара һәм (яки) төсле металл калдыкларын шартлау куркынычсызлыгына тикшерү үткәрү өчен җаваплы зат бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 9 пунктының дүртенче абзацы | | | | |
| 12 | Объектта аның турында Үлчәүләрнең бердәмлеген тәэмин итү буенча федераль мәгълүмат фондында белешмәләр булган һәм Үлчәү бердәмлеген тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тикшерелгән төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын идентификацияләү һәм сортларга аеру җиһазлары бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 9 пунктының унынчы абзацы | | | | |
| 13 | Кара металл ватыкларын һәм калдыкларын кабул итү объектында милек хокукында яки башка законлы нигездә җиһазларның түбәндәге төрләренең теләсә кайсы бер берәмлек бармы:<br>кара металл ватыкларын | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 10 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | пакетка тутыру яки брикетлау өчен пресс;<br>пресс-кайчы;<br>җиңел металл ватыкларын ваклау һәм сортларга бүлү өчен җайланма;<br>сортларга бүлү яки йомычкаларны ваклау өчен җайланма; | | | | | |
| 14 | Төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын эшкәртү объектында милек хокукында яки башка законлы нигездә җиһазларның түбәндәге төрләренең теләсә кайсы бер берәмлек бармы:<br>төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын пакетка тутыру яки брикетлау өчен пресс;<br>пресс-кайчы;<br>төсле металл ватыкларын һәм (яки) калдыкларын ваклау өчен җайланма;<br>кабельне аралау җайланмасы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 11 пункты | | | | |
| 15 | Объектта, кара һәм (яки) төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын кара һәм (яки) төсле металл ватыкларын пакетларга тутыру яки брикетлау өчен пресс белән эшкәрткән очракта, I разрядтан түбән булмаган квалификацияле металл ватыкларын һәм калдыкларын пресслаучы бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 10, 11 пунктлары | | | | |
| 16 | Объектта кабул итү-тапшыру актлары бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 13 пункты | | | | |
| 17 | Кәгазь чыганакта Кабул итү-тапшыру актларын исәпкә алу кенәгәсе (2023 елның 01 гыйнварына кадәр кулланыла) яки кабул итү-тапшыру актларының электрон реестры бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 14 пункты | | | | |
| 18 | Төсле металлның көнкүреш (физик затлардан кабул ителгән) һәм сәнәгать калдыкларын һәм ватыкларын аерым саклау өчен шартлар бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 20 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 19 | Төяп җибәрелгән кара һәм (яки) төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын теркәү журналы бармы? | Кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләренең 22 пункты | | | | |

« ___» _________________ 20__ ел
(тикшерү кәгазен тутыру датасы)

______________________________
(контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүче һәм тикшерү кәгазен тутыручы вазыйфаи зат имзасы)